# «Матур жирләр күп булса да, Зианчура бер генә»




Күгәрчен авылы китапхана мөдире
Юлтимирова Гөлдәр Сәмигулла кызы



Төньяктан көньбатышка кадәр, баһадир сакчылар кебек Елан тау, Очкыр тау, Жимерек тау, Карабаш тавы, Маяк тау, Олы тау, Богдан тавы тезмәләре уратып алган.


Авылыбыз өстендә күк тә биек,чөнки күк гөмбәзен шул таулар үз
тубәләрендә тотып торалар



Бу таулардан тирә- якка карап,
Ничәнчегә хәйран калуым.
Туган ягым- биек таулар иле!
Син дә анда бер тау, авылым.
Рух тавы, хәзинәлар тавы,
Балкышыннан күзләр
чагылган.
Шушы тавым минем
кешеләрнең,
Күңел жылысыннан
салынган.

Марат Кәримов

**Саф су бөтен донья проблемасына әверелгән вакытта авылыбыз суы эчеп туйгысыз чылтырап аккан чишмәләр эчендә утыра. «Кешеләр саф булыгыз!»дигән кебек авыл урамын буйлатып Карабаш елгасы юып үтә. Авылның төньяк - көнчыгышында салкын сулы «патша» балыклары яшәгән йөгерек Ямашлы елгасы Сурәм елгасына кушылу нияте белән сикәлтәләр аша дәртле дулкыннарын куалый.**



Емерек чишмәсенең ургылып чыккан урыны.




Чишмәләр ага икән, үз юлын таба икән.

Емерек тау чишмәсе тешләрне сындырырлык салкын, саф суы белән барлык үткенче кешеләргә онытылмаслык истәлек калдыра.





**Күгәрчен  авылының Емерек тавы авылның көнчыгышында мәһаббәт кая ташлары биек стенадай, Оренбургтан Зилаир, Баймак якларына узган магистраль юл өстенә авып төшәрдәй булып торган тау. Үткән заманда юл кая ташларга  бик якын  уза, чөнки тау астыннан ургылып аккан чишмә, сазлык һәм Ямашлы елгасы, кая ташларны  читләтеп үтәргә мөмкинчелек бирми.**





**Баймак приискаларында гына түгел, Сүрәм, Ямашлы елгалары башларында да алтын эзләү киң колач алган вакытларда, Зилаирда старательләрдән алтын кабул итү кибете эшли башлый. Жыелган алтын, безнең авыл аша узган «губернатор юлы» белән, Оренбургка озатылып торган. Заманга яраклы легенда да барлыкка килә. Емерек тау астында да алтын яткылыгы бар икән, ләкин хәзергә ул яшь һәм өлгереп житмәгән икән әле. Көтмәгәндә аңа яңа хәзинә дә өстәлә. Оренбургка юнәлгән, алтын төялгән олауларның берсе, Емерек тау кысыгыннан үткәндә, аның юл өстенә куркыныч салып торган кая ташларнын берсе ишелеп төшә.Алтын олавы ташлар өеме астында кала. Тик тау астындагы алтын яктылыгына да һәм ул хәзинәгә дә тияргә ярамый. Чөнки аларның хужасы бар. Ул хужа – Емерек тавының иясе. Аңа тигән кеше, бу доньяда яшәми!.. Менэ шулай Емерек тау – ияле тау. Күренүенчә, легенда нигезендә күпме тарихи чынбарлык ята.**



# Емерек тавының мәгърүр каялары





# Емерек тавының кышкы күренеше



# Емерек тавы итәгендә Ямашлы сусаклагычы урнашкан.



Сусаклагычка экскурсия



Кемпинг




Балалар җәйге ялда

Емерек тавы битләвендә «Бөтен Рәсәй яшьләренең турфестивале $Q_2$» үтте.





Һәр елның җәйге айларында Емерек тавыннан туристлар өзелми


Яшәр әле бу тау яшәгәндә,
Авылымның асыл ирләре.
Безне тормыш һаман алга әйди,
Үзенә чакыра яңа үрләре.

# Мәктәп укучылары Емерек тавында экскурсия вакытында











***Чәчкә шәлкемнәре белән бизәлгән болыннары, җиләк җимешләре тирә-як мөхитне генә бизәп калмый, табигать биргән байлык булып авыл өстенә ишелеп тора. Авылыбызның байлыгын саклыйк, абруен югалтмыйк, чөнки авыл безнең туган җиребез, туган илебез.***

***Онытма, туган җир бер генә,***

***Кадерләрен аның бел генә…***


ИГТИБАРЫГЫЗ ЭЧЕН ЗУР РЭХМЭТ